РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕМОРБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Советская ул., дом 47,
с. Шеморбаш, 422667

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШОМЫРБАШ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 47 нчы йорт,
Шомырбаш авылы, 422667

Тел.: (8-4361) 20-415, факс: (8-4361) 20-415, эл.адрес: Smrb.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2022 г Шомырбаш авылы №1

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктын үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомарбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

2.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Шомарбаш авылы, Совет урамы, 47 йорт; Таулар авылы, Ленин урамы, 50А йорт; Алан-Полян авылы, Я.Емельянов урамы, 6 йорт; Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгы авылы, Парк урамы, 10 йорт , Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырылган: http://ribnaya-

sloboda.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шомырбаш авыл җирлеге Башлыгы И.Н.Сафин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шомырбаш авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2022 елның 31
гыйнварындагы 1 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шомырбаш авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет куюны гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 500,00 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2146,95 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |